“Аулак өй”

6 нчы группа балалары белән “Аулак өй” дигән фольклор кичә уздырылды. Балаларны татар халкының гореф-гадәтләре,милли мәдәнияте белән таныштыруны дәвам иттердек. Җырлы- биюле күңел ачу бәйрәме аркылы балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләнде, балаларның кузаллаулары киңәйде, күңелләрендә шатлык хисе, бәйрәм рухы туды. Зал бәйрәмчә бизәлде: чиккән сөлгеләр, өстәлдә самовар белән чашкалар, йон эрли торган каба, сандык куелды. Фольклор кичә барышында балалар элекке вакытка кайтып, аулак өйләрдә нәрсә булганына төшенделәр. Бәйрәм барышында җырлы- биюле уеннар уйналды, татар халык биюе башкарылды, санамышлар әйтелде. Бәйрәм күңелле утте, балаларга бәйрәм бик ошады.



